Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

# ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Колаңгы авыл җирлеге, Колаңгы тимер юл станциясе поселогы, Шоссейная ур, 24 й. адресы буенча урнашкан 16:21:130408:255 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Җир кишәрлеге буенча гавами кадастр картасыннан мәгълүмат;
2. Колаңгы авыл җирлегенең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
3. Колаңгы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләреннән шәһәр төзелеше регламентлары турында мәгълүмат.

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы: 2026 елның 28 маеннан 2026 елның 09 июненә кадәр

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шундый җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы:

-Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

- Кайбыч районы, Колаңгы тимер юл станциясе поселогы, Шоссейная ур, 5 й. адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районынын Колаңгы авыл җирлеге Башкарма комитеты.

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2026 елның 28 маеннан 2026 елның 08 июненә кадәр 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, 2026 елның 09 июнендә 8.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның 28 маеннан 2026 елның 08 июненә кадәр 8.00 дән 17.00 гә кадәр, 2026 елның 09 июнендә 8.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр язма рәвештә Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә кабул ителә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: 2026 елның 09 июнендә 11.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Колаңгы тимер юл станциясе поселогы, Шоссейная ур, 30 й. адресы буенча урнашкан иҗтимагый үзәк бинасында.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайты «Сайтка килүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм:

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й. адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк;

-Кайбыч районы, Колаңгы тимер юл станциясе поселогы, Шоссейная ур, 5 й. адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н. Макаров